# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 26 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2011, 25 май) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $11^1$ статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн класс чины бирелгән көн дип санала. Класс чины квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелгән очракта, дәүләт хезмәткәре тарафыннан квалификация имтиханы бирелгән көн класс чины бирелгән көн дип санала.»;

2) $11^2$ статьяда:

а) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Билгеле бер вәкаләтләр чорына дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренә, дәүләт хезмәте вазыйфаларының иң югары төркеменә керә торган «җитәкчеләр» категориясендәге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш, класс чиннары квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча бирелә.»;

б) 6 өлешне үз көчен югалткан дип таныrга;

3) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. **Квалификация имтиханы**

1. Квалификация имтиханын әлеге Законның $11^2$ статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән дәүләт хезмәткәрләре бирәләр.

2. Квалификация имтиханы, дәүләт хезмәткәре инициативасы белән дәүләт хезмәтенең класс чинын бирү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә, дәүләт хезмәтенең класс чинын бирү турында ул язма гариза биргән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3. Квалификация имтиханы билгеләнгән рәвештә конкурс яисә аттестация комиссиясе тарафыннан дәүләт хезмәткәренең белемен, күнекмәләрен һәм осталыгын (һөнәри дәрәҗәсен) билгеләү максатларында уздырыла.

4. Дәүләт хезмәткәре Федераль закон нигезендә квалификация имтиханы нәтиҗәләренә карата шикаять бирергә хокуклы.

5. Дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан квалификация имтиханын бирү тәртибе федераль законнар нигезендә билгеләнә.».

**Статья 2**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2011 елның 18 ноябре
№ 85-ТРЗ